# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**30.03.2024 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Иске Имән авыл җирлеге Иске Имән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 20 мартындагы 1 номерлы карары нигезендә 2024 елның 30 мартында 13.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән сораулар буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Иске Имән авыл җирлеге Иске Имән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә ризамы:

1. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Иске Имән торак пунктында төзелеш материаллары сатып алу һәм зират коймасын урнаштыру буенча эш өчен түләү);
2. Электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен,трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау (Иске Имән торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру);
3. Торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Имән торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Имән торак пунктында ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
5. Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарның вакытлыча туплану урыннарын җыю (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);».

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 149 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 101 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 101 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:
1.Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныйрга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныйрга.
2.Чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп :
1. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Иске Имән торак пунктында төзелеш материаллары сатып алу һәм зират коймасын урнаштыру буенча эш өчен түләү);
2. Электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен,трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау (Иске Имән торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру);
3. Торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы жирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Имән торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Имән торак пунктында ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
5. Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарның вакытлыча туплану урыннарын җыю (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);»
«Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 16 ноябрендәге 1 нче номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 нче номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныйрга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Имән авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче Р.Ә.Исламова